# «БУ ДӨНЬЯ – МӘҢГЕЛЕК ТУУДЫР»
## Сирень Якупованың
## «Кар юлы» шигъри җыентыгы буенча әдәби-музыкаль композиция.
*(өлкән сыйныф укучылары өчен)*

*Сәхнә матур итеп бизәлгән, төрле биеклектә урындыклар куелган. Талгын гына көй астында алып баручы чыга.*

**Алып баручы:**

Бу дөнья – мәңгелек туудыр,
Таң туа офыкта алланып.
Таң белән бергәләп җан туа,
Биләүдә ятасы балланып.

Бу дөнья – мәңгелек туудыр,
Шыта гөл – кояшта күзләре.
Черт тә черт йомырка кабыгы –
Үләндә яшь бәбкә эзләре.

Бу дөнья – мәңгелек туудыр,
Яңа җыр агыла йөрәктән.
Бәгырьнең ташларын эретеп,
Чишмәдәй ургыла кинәттән.

*«Бу дөнья – мәңгелек туудыр»*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле студентлар, кадерле кунаклар. Без бүген сезнең белән шигырь бәйрәменә җыелдык. Шигырь бәйрәме, чөнки бүгенге кичәбезнең төп кунагы – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Сирень Якупова.

**Алып баручы:** Сирень Мөхиббулла кызы Якупова 1961 елның 26нчы августында Татарстан Республикасының Әлмәт районы Түбән Абдул авылында туа.

1978 елда Елховой урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Әлмәт төзелеш техникумында белем ала. Нәкъ менә шул елларда районның «Хезмәт байрагы» газетасында аның беренче шигырьләре дөнья күрә. Хезмәт юлын ул туган авылы мәктәбендә башлый. Ярты ел укытучы булып эшләгән Сирень, шигырендәгечә «хыялы артыннан йөгереп», янә Әлмәт каласына китеп бара. Ә 1982 елның җәендә яшьләр шәһәре Чаллыга килә. Башта КамАЗның агрегат, аннан соң кече литражлы автомобильләр җыю заводларында эшли. Шушы елларда аның шигырьләре, язмалары КамАЗның «Нур» газетасында даими басылып килә.

*Талгын гына көй астында урындыкларга укучылар чыгып утыра.*

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Бар тавышка елап туа кеше,
Китә аннан, елап тын гына...
Әллә гомер – керфек очларыннан
Тамган шушы яшьле моң гына?!

Әллә гомер – җанның сулкылдавы,
Тән читлеге миңа тар диеп?
Җан белән тән арасында мәллә
Бәргәләнә йөрәк, кан тибеп?

Бәргәләнә йөрәк, яшим, диеп
Һәм яшәтәм, диеп, дөньяны.
Өзелепләр төшкән гомер-тамчы –
Җирне бизәп шытар гөл бары...

*«Бар тавышка елап туа кеше»*

**2нче укучы:**

Җир – Кояшның кызы. Мин – Җирнеке.
Кояш миңа әби буламы?
Һәр иртәдә көлеп һәм иркәләп,
Чәчләремнән сыйпый шуңамы?

Җир – Кояшның кызы, зәңгәр күзе,
Төрелгәндер сөю нурына.
Чиксез еллар Галәм упкынынннан
Саклый аны шушы нур гына.

Җир – Кояшның кызы, мин – оныгы.
Икебез дә очар күбәләк.
Бәхетлегә дөнья түгәрәк дип
Әйләнәбез Кояш тирәләп.

*«Җир – Кояшның кызы»*

**Алып баручы:** Туксанынчы еллар азагында Сирень Якупова «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри башлый, ул «Йолдызлы уйлар» (2003) исемле тәүге китабын чыгара. 2006елда шагыйрә «Шәһри Чаллы» газетасы редакциясенә эшкә килә һәм 2013 елга кадәр шунда хезмәт куя. Шул чорда шәһәр һәм республика матбугатында аның бик күп кенә шигырьләре, хикәяләре, язмалары дөнья күрә, китаплары басыла.

Бүгенге көндә ул биш китап авторы. Алар «Ике гасыр баласы мин» (2005), «Яшәү сере» (2008), «Өстәгеләрдән дә өстә» (2011), «Кар юлы» (2014).

Шагыйрәнең «Кар юлы» шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Сирень Якупованың шигырьләре тирән фәлсәфәгә, үзенчәлекле табышларга бай булуы белән укучыны үзенә җәлеп итә.

*Укучылар чыгышы.*

**3нче укучы:**

Бер карага, бер сарыга буйыйм,
Бер җирәнгә манам чәчемне...
Мин генәме, хәер, үз төсләрен
Заман буявына яшергән.

Йөзләремә тоныкк кершән сөртәм,
Күзләр тоныклана үзләре.
Мин генәме, әйе, мин генәме
Дөньяларга ярап үзгәрдем...

Көзгеләрдән инде көзем карый,
Елмая ул серле, ник дисәм,
Янәшәмә кызым килеп баскан,
Яшьлегемдәй ихлас, көлемсәр...

*«Бер карага, бер сарыга буйыйм»*

**4нче укучы:**

Җиңдең, дөнья...
Җибәр, кысма, зинһар, йөрәгемне.
Мин бит хатын-кыз.
Бил алышыр ирләр, илләр барда,
Аларның син, әнә, билен кыс.

Оттың, дөнья...
Бушайт, өзәсең лә
Соңгы кылын моңлы күңелнең.
Отылуым өчен, сөйләште кич,
Соңгы сөю белән түлимен.

Җиңдең, оттың, дөнья, тәнне-җанны...
Булдыралсаң – яшә, дисеңме?
Кара көйгән иреннәрем, ишет,
Ак, дип, дәшә синең исемне,
Ак, дип, дәшә синең исемне...

*«Дөнья»*

**Алып баручы:** Сирень Якупованың шигырьләрендәге ихласлык, тормышка, туган якка мәхәббәт хисләре тирәннән тибеп чыккан, шуңадырмы алар һәр йөрәккә барып җитәрдәй көч-кодрәткә ия.

*Укучылар чыгышы.*

**5нче укучы:**

Авылыма алып кайтыр юл –
Юлларның юлыдыр ул.
Һәр чокыры мөлдерәмә
Сагыну тулыдыр ул.

Авылыма алып кайтыр юл –
Юлларның юлыдыр ул.
Аяклар өчен бормалы,
Җан өчен турыдыр ул.

**6 нчы укучы:**

Авылыма алып кайтыр юл –
Юлларның юлыдыр ул.
Туган йорт тәрәзәсенең
Балкышы, нурыдыр ул.

Авылыма алып кайтыр юл –
Юлларның юлыдыр ул.
Озын да, кыска да түгел –
Гомерем буедыр ул.

*«Авылыма алып кайтыр юл»*

**Алып баручы:** Шагыйрә күзәтүчән, аның бик күп шигырьләре күзәтү нигезендә туганнар булса кирәк. Ак чәчәкләр, кызыл миләш тәлгәшләре, күгәрчен, эт, песи аны шигъри юлларга этәрә. Тагын бер шигырь ишеттереп үтәсем килә:

*Укучылар чыгышы.*

**7 нче укучы:**

Йомшак уенчык – этләр, песиләр.
Каты уенчык – танк ишеләр.
..Каты-йомшакка дөнья бүленгән:
Каты бәгырьләр, йомшак күңелләр.
Балалар әле моны белмиләр...

Кызлар кулында матур курчаклар,
Ә малайларда – җил җитез атлар.
...Ир-хатыннарга дөнья бүленгән:

Ир – тормыш аты, хатын – дилбегә.
Тик балаларга әле бу нигә?

Алар уйнасын онытып дөньясын.

*«Балалар уенын күзәткәндә»*

**8 нче укучы:**

Өзелгән килеш калдырмыйм
Күңелемнең кылларын.
Ялгыйм, ямыйм, сынап карыйм,
Тыңлап карыйм – моң бармы?

«Әһә! – димен сөенечтән, -
Моңсыз кавем түгел без!»
Мең кылында мең төрле моң,
Мең төрле уй, күңел, түз!

Түзәлгән кадәр өзелми,
Түзәлмәгәндә дә түз.
Милләтҗанына дәва, бел:
Синең моң да минем сүз.

*«Өзелгән килеш калдырмыйм»*

**Алып баручы:** шигырьләрнең төзек хәрәкәттә, эзлекле булуы укучыны җәлеп итә. Кар юлы китабында беренче шигырьдән башлап китап ахырына кадәр укучыны төзеклек, хисләрнең чынлыгы озата. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Кычыткан өзәм даруга,
Кулым түзә чагуга.
Бармаклар ни, йөрәгемнең
Уттай янган чагы ла...
*Кушымта:*
Онытканны, югалтканны –
Барын да искә төшер.
Туган авылым кычытканы,
Пешер җанымны, пешер!

Туган авылым кычытиканы,
Пешер хәтерне, пешер!
Ялантәпи балачакны
Елатып искә төшер.
*Кушымта.*

Искә төшер яшлегемне,
Борынгылар каберен.
Туган җирнең, туган телнең
Туганнарның кадерен.
*Кушымта.*

*«Кычыткан»*
*(Сирен Якупова сүз., Факил Сафин көе)*

**Алып баручы:** Кар юлы шулай, шигырьдән шигырьгә күчеп,ачыла бара. Ихласлыкка ни җитә! Сирень Якупова каударланмый һәм иң мөһиме – кабатланмый сер чишә дә чишә. Шагыйрьнең шәхси өлгергәнлеген, күңеленең матурлыгын тоеп, җан кинәнә.

*Укучылар чыгышы.*

**2 нче укучы:**

Һәркем белгән, аңлаганны,
Укыганны, ятлаганны,
Һәркөн күргән, ишеткәнне,
Инде күрми дә үткәнне,
Сүзгә үреп җыр-сер итә –
Азмы, күпме бер шагыйрьгә?

Ел-гасырлар аша үтеп,
Сүзен сүзгә аннан сүтеп,
Серне ачу бар дөньяга,
Таң калдырып өр-яңадан –
Азмы, күпме бер шагыйрьгә,
Бер йөрәккә, бер бәгырьгә?

*«Һәркем белгән, аңлаганны»*

**Алып баручы:** Сирень Якупованың шигырьләре табышларга бай. Тик табышлардан канәгатьләнеп, ярты юлда туктарга җыенмый шагыйрь.

*Укучылар чыгышы.*

**3 нче укучы:**

Мамык шәлдәй йомшак садә кардан
Нинди рәхәт иртән баруы!
Күпме гомер яшәп, яңа тойдым
Кар юлының җирдә барлыгын.

Карлы юллар бик күп, меңәрләгән,
Ә кар юлы була бер генә.

Аңны ярып, ап-ак яшен үтә,
Шул сукмакка килеп кер генә.

**4 нче укучы:**

Күңелеңнең һәрбер тутык кылы
Ак алтындай китә ялтырап.
Чыңлый башлый, җырлый башлый дөнья,
Вакыт туктый хәтта, ял сорап.

Илаһи моң, аклык, сафлык тулы
Мизгел аша берме үткәнгә,
Әйтә алам,
Кар юлыннан җиргә килә җаннар,
Кар юлыннан аша күкләргә...

*«Кар юлы»*

**Алып баручы:** Күңелне алга җилкендергән ак җилкәнне давыллар екмасын, тормыш корабында серле кыйтгалар ача-ача һаман алга, киләчәктә якты елларга карап йөз дә йөз.

## Файдаланылган әдәбият

Якупова, С. Кар юлы: шигырьләр / С.Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 223 бит.

Журналның Сирень Якупова иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2014. – № 9.